ГЛАВА КУРАЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.25, с. Куралово,
422581

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КУРАЛОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 25 нче йорт, Куралово авылы,
422581

Тел.: (84379) 33-5-36, факс: (84379) 33-5-36.

21.10.2023 № 1

КАРАР
Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Куралово авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 21 октябрендә «Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Куралово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы? дигән сорау буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

- Куралово авылында юлларны чокырлы ремонтлау өчен вак таш сатып алу һәм товарны билгеләнгән пунктка кадәр җиткерү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 823 катнашучысы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 445 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен җыенда 445 катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлегендә халык җыены булды дип, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга

2. “Югары Ослан муниципаль районының Куралово авылы җирлегендә 2024 елда Югары Ослан муниципаль районының Куралово авылы җирлеге Куралово авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә , авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалы гражданнардан тыш, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юллау белән килешәсезме - Куралово авылында чокырлы юлларны төзекләндерү өчен, товар кайтаручы хисабына билгеләнгән пунктка илтеп җиткереп, вак таш сатып алу, дигән сорау буенча карарны кабул итәргә.

2. Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Куралово авылының халык җыены нәтиҗәләрен Куралово авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Р.Е. Тарасов